| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2022 г.Лениногорск № 46

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы авыл җирлекләренең генераль планнарын әзерләү кирәк булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясының 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер, Керкәле авыл җирлекләре территориясендә җирлек территорияләрен гамәлдәге куллануны үзгәртү күздә тотылмаганга күрә, комплекслы социаль-икътисадый үсеш программалары һәм Татарстан Республикасы һәм Лениногорск муниципаль районының территориаль планлаштыру схемалары белән расланган федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмаган, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер, Керкәле авыл җирлекләренең генераль планнарын эшләү кирәк булмавын танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Хөсәенов